СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2026 ел** **№ 18**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ташкичү авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Ашытбаш, Ташкичү, Кысна, Ак-Чишма, Наратлык, Хәтнә, Мәмсә, Иске Ашыт, Иске Кенәр, Пичмәнтау авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 19 номерлы;

- “Ташкичү авыл җирлеге Советының “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 14 декабрендәге 31 номерлы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин